| ГЛАВА АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

10.05.2023 п.г.т. Алексеевское № 5-р

**Махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган (үлгән) очракта гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр турында**

Махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль яклау дәрәҗәсен арттыру максатыннан:

1.Социаль ярдәмнең өстәмә чараларын билгеләргә:

-махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган(үлгән) очракта гаиләләргә 50000,00 (илле мең) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

-махсус хәрби операциядә катнашкан һәлак булган (үлгән) граждан каберенә һәйкәл сатып алу/ясау өчен 20000,00 (Егерме мең) сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.

2.Махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган (үлгән) очракта гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруның Тәртибен расларга.

3.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (О.Н. Леденцов) әлеге күрсәтмәдә күрсәтелгән өстәмә социаль ярдәм чарасын күрсәтү өчен җирле бюджет акчаларыннан финанслауны тәэмин итәргә.

4.Әлеге боерык 2023 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы башлыгы** **С. А. Демидов**

Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы башлыгының
10.05.2023 № 5-р күрсәтмәсенә кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган(үлгән) очракта гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе.**

1.Әлеге Тәртип махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган(үлгән) очракта (алга таба-бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр) гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр бирү механизмын билгели.

2.Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган(үлгән) очракта гаилә әгъзаларына бирелә.

3.Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү өчен гаилә әгъзасы (гариза бирүче) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү турында гариза (алга таба - гариза) һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданның үлеме турында таныклыгының күчермәсен кушып, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (формасы - әлеге Тәртипкә кушымта) тапшыра.

4.Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне билгеләү өчен мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче шәхесне раслаучы документ күрсәтә.

5.Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан 5 эш көне дәвамында бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр бирү турында карар кабул ителә / бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне бирүдән баш тарту турында боерык акты чыгарыла.

6.Кредит оешмаларында ачылган гариза бирүчеләрнең шәхси счетларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр суммаларын күчерү эш көннәрендә исәпләнә торган утыз көн эчендә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып башкарыла.

7.Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләрне бирүдән баш тарту өчен нигез булып, булган мәгълүматлар һәм документлар җыелмасы нигезендә аны алу хокукы булмавы тора.

**Советның аппарат җитәкчесе** **А.Г.Соловьев**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма комитеты

*Форма*

ГАРИЗА № ____
__________ 20__ ел

Мин____________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булганда))

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем биргән | Бирү вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |

теркәлгән адрес буенча:
_______________________________________________________________________________,
(индекс, телефон, электрон почта адресы күрсәтелгән мөрәҗәгать итүченең почта адресы)

СНИЛС (гариза бирүченең)___________________________.
Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башлыгының__________ № _______ боерыгы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнар һәлак булган(үлгән) очракта гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр билгеләүегезне сорыйм.
_______________________________________________________________________________:
(Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булганда), туган вакыты)

Кредит оешмасында ачылган гариза бирүченең шәхси счеты реквизитлары

_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

Мәгълүмат алуга, шул исәптән социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә (бирүдән баш тартуга) риза
_______________________________________________________________________________
(почта адресы буенча хат белән, электрон почта адресы буенча электрон почта аша)

Вакыт_____________ ______________________________
(гариза бирүче имзасы)

Шәхси мәгълүматны эшкәртүгә ризалык

Мин,_______________________________________________________________,

*(Ф. И. А. (соңгысы булганда)тулысынча)*

_________________________________________________________________

*(контакт мәгълүматлары: телефон номеры, электрон почта адресы яки шәхси мәгълүмат субъектының почта адресы)*

махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне билгеләү максатыннан, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына автоматлаштыру чараларын кулланып яки андый чараларны кулланмыйча, шул исәптән җыюны да кертеп, язуга, системалаштыруга,туплауга,саклауга,төгәлләштерүгә(яңарту, үзгәртү), чыгаруга, куллануга,тапшыруга(тарату, бирү, керү мөмкинлеге) ,шәхессезләндерүгә,блоклауга,бетерүгә,юк итүгә,балигъ булмаган балаларымның шәхси мәгълүматын (мәгълүматларын) һәм минем шәхси мәгълүматымны (мәгълүматларымны) кулланырга ризалыгымны бирәм:

фамилиям, исемем, әтиемнең исеме; туган көнем; гаилә хәлем; паспорт мәгълүматларым; теркәлү һәм яшәү урыны адресым; элемтә телефоны номерым.

Шәхси мәгълүматларны, балигъ булмаган балалар турындагы мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык, социаль ярдәм чараларын күрсәтү өчен документларны саклау өчен, архив законнары белән билгеләнгән срок тәмамланганчы гамәлдә.

_________________________________________________________________

*(вакыт)* *(фамилиясе, исеме, атасы) (соңгысы булганда)* *(имза)*